ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Күскәм авылында, Куныр авыл җирлеге
Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты

2024 елның 24 март № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә жыен беркетмәсе төзелде Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлегенең Күскәм авылы торак пунктында гражданнарны:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлегенең Күскәм авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 29.12.2023 ел, №2 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту: Пионер урамы буенча юлны ремонтлау;

-су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау: үзәк сууткәргеч өчен йозак сатып алу һәм урнаштыру

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка игълан итәргә. baltasi.tatarstan.ru. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында. pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен жибәрергә.

Халык жыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р.О.Егоров